ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«14» февраль 2020 г. № 32-р

«ГТО» кышкы фестиваленең
муниципаль этабын үткәрү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 июнендәге 1165-р номерлы карары белән расланган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын этаплап кертү буенча чаралар планы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлегенә 2020 елның 19 февралендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «ГТО» кышкы фестиваленең муниципаль этабын оештырырга һәм үткәрергә.

2. Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре арасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы кышкы фестиваленең муниципаль этабын әзерләү һәм үткәрү турында Нигезләмә;

- «ГТО» кышкы фестиваленең беренче һәм икенче муниципаль этабын уздыру өчен судьялар коллегиясе составы;

- «ГТО» кышкы фестиваленең муниципаль этабын уздыру турында чыгымнар сметасы.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының МБУ «Спорт мәктәбе»нә «ГТО» кышкы фестиваленең муниципаль этабын уздыру өчен чаңгы трассасын 2020 елның 19 февраленә кадәр әзерләүне оештырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының МБУ «Олимп» спорт-сәламәтләндерү комплексына «ГТО» кышкы фестиваленең муниципаль этабын уздыру өчен спорт залын әзерләүне оештырырга.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы МКУ «Мәгариф идарәсе»нә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф оешмаларына «ГТО» кышкы фестиваленең муниципаль этабында катнашу турында мәгълүмат җиткерергә.

6. Татарстан Республикасының «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССОсына «ГТО» кышкы спорт чарасын медицина ярдәме белән тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

7. «Әгерҗе хәбәрләре» район газетасы редакциясенә ярышларның нәтиҗәләре һәм барышы турында массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга тәкъдим итәргә.

8. Әлеге күрсәтмәне Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

9. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
14 февраль 2020 ел № 32-р
номерлы күрсәтмәсе белән

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре арасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы кышкы фестиваленец муниципаль этабын әзерләү һәм үткәрү турында Нигезләмә**

## I. Максаты:

Укучыларны физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү.

## II. Бурычлар:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы укучылары арасында ГТО комплексын популярлаштыру;
- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы укучыларыныц физик әзерлек дәрәҗәсен күтәрү;
- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;
- физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә этәргеч бирүче шартлар тудыру.

## III. Үткәрү урыны һәм вакыты

Беренче этап 2020 елның 19 февралендә, Әгерҗе шәһәренең «Орешник» урман массивында 08.30 сәгатьтә башлана.
Икенче этап 2020 елның 19 февралендә, 13.00 сәгатьтә Әгерҗе шәһәренең «Олимп» спорт комплексында башлана.

## IV. Катнашу өчен гаризалар бирү

Фестивальдә катнашучыларның исемлекләрен 2020 елныц 18 февраленә кадәр спорт мәктәбенец электрон почтасына spshcola@mail.ru беркетмәләр төзү өчен җибәрергә кирәк. Фестивальдә катнашучылар саны-мәктәптән 4 кеше, һәр баскычта 2 малай һәм 2 кыз.
Аерым затлар рөхсәт ителә.

## V. Чараны оештыручылар

Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районыныц «Олимп» СОК МБУ, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районыныц «Спорт мәктәбе» МБУ.

## VI. Катнашучыларга таләпләр һәм аларны кертү шартлары

Табиб һәм мәктәп директоры тарафыннан имзаланган, һәр баскыч буенча аерым язылган ирекле формадагы гаризалар, ярышлар көнендә бирелә, балигъ булмаган балаларның ата-анасының берсеннән катнашырга риза булуы турында белешмә кирәк. Барлык катнашучылар да ГТО АИСында теркәлергә тиеш.

## VII. Фестиваль программасы

**7.1. 2020 елның 19 февралендә чаңгы ярышы**

| | **Малайлар төркеме** | Дистанция |
|---|---|---|
| 9.00 | 9-10 яшь | **1 км** |
| 9.20 | 11-12 яшь | **2 км** |
| 9.40 | 13-15 яшь | **3 км** |
| 10.15 | 16-17 яшь | **5 км** |
| | **Кызлар төркеме** | |
| 9.00 | 9-10 яшь | **1 км** |
| 9.20 | 11-12 яшь | **2 км** |
| 9.40 | 13-15 яшь | **3 км** |
| 9.40 | 16-17 яшь | **3 км** |

**7.2. Гимнастика эскәмиясендә төз аяклар белән алга иелү (2-5 баскыч)**
**7.3. Көч гимнастикасы:**
Малайлар – тартылу (2-5 баскыч)
Кызлар – идәндә ятып бөгелү һәм тураю (2-5 баскыч)
**7.4. Ике аяк белән этелеп урыннан озынлыкка сикерү:**
Малайлар, кызлар, егетләр, кызлар (2-5 баскыч)
**7.5. Аркада яткан килеш гәүдәне күтәрү** (2-5 баскыч)
**7.6. Пневматик винтовка һәм электрон коралдан ату (3-5** баскыч**).**

## VIII. Условия подведения итогов

Шәхси-команда ярышлары. Катнашучылар арасында шәхси беренчелек ГТО комплексының һәр баскычы өчен егетләр һәм кызлар арасында аерым билгеләнә һәм фестиваль программасының барлык төрләрендә җыелган очколарның иң зур суммасы буенча нәтиҗәләр бәяләүнең 100-очколы таблицасы нигезендә белән бәяләнә. Ике яки аннан да күбрәк катнашучының очколар суммасы тигез булган очракта, өстенлекне озын дистанциягә йөгерүдә күрсәткән катнашучы ала, бу күрсәткеч тигезлеге булганда-кыска дистанциядә.

## IX. Бүләкләү

Шәхси беренчелектә малайлар, кызлар, егетләр һәм кызлар арасында 1-3 урыннарны алган катнашучылар фестивальнең спорт программасында һәр яшь төркемендә грамоталар, медальләр белән бүләкләнәләр.

1,2,3 урын алган командалар кубоклар һәм грамоталар белән бүләкләнә.

Фестивальнең һәр төре һәм баскычлары буенча катнашучылар малайлар һәм кызлар, егетләр һәм кызлар арасында грамоталар белән бүләкләнәләр.

## X. Катнашучылар һәм тамашачылар иминлеген тәэмин итү

Катнашучыларның һәм тамашачыларның куркынычсызлыгы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 18 апрелендәге 353 номерлы карары белән расланган рәсми спорт ярышларын уздырганда куркынычсызлыкны тәэмин итү кагыйдәләре, шулай ук спортның тиешле төрләре буенча кагыйдәләр таләпләренә туры китереп гамәлгә ашырыла.

Фестивальнең спорт программасы Бөтенроссия спорт объектлары реестрына кертелгән спорт объектларында «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үткәрелә.

Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «физкультура һәм спорт чараларын үткәргәндә медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында»2010 елның 9 августындагы 613 номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
14 февраль 2020 ел № 32-р
номерлы күрсәтмәсе белән

**«ГТО» кышкы фестиваленең беренче һәм икенче муниципаль этабын уздыру өчен судьялар коллегиясе составы**

1. Тукаева Гөлназ Рәшидовна (МБУ «Спорт мәктәбе»)
2. Мөхәммәтҗанова Наталия Викторовна (МБУ «Спорт мәктәбе»)
3. Добровольская Рашания Илдаровна (МБУ «СОК «ОЛИМП»)
4. Мөхәммәтҗанова Розалия Николаевна (Тест үзәге хезмәткәре)

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
14 февраль 2020 ел № 32-р
номерлы күрсәтмәсе белән

**«ГТО» кышкы фестиваленең муниципаль этабын уздыру турында чыгымнар сметасы**

| Товарлар | Саны | Бер берәмлек өчен бәясе | Бәясе, сум. |
|---|---|---|---|
| Грамоталар | 33 | 11 сум. | 363 сум. |
| Кубок 1 урын | 1 | 1450 сум. | 1450 сум. |
| Кубок 2 урын | 1 | 1400 сум. | 1400 сум. |
| Кубок 3 урын | 1 | 1200 сум. | 1200 сум. |
| Барлыгы | | | 4413 сум. |